**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

18.10.2023 **Чирмешән авылы** №292

«Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге №325 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы № 492-ФЗ, «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-сәламәтләндерү җирлекләре һәм курортлары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2023 елның 4 августындагы № 469-ФЗ, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы № 438-ФЗ Федераль законнарга ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге №325 карары белән расланган җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8.3.1 пунктның 3 пунктының «ж» пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «ж) Җир асты байлыкларыннан файдалану, линия объектларын, аларның аерылгысыз технологик өлешләрен, гидротехник корылмаларын төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, шулай ук сусаклагычлар, башка ясалма су объектлары төзү максатларында барлыкка килә торган җир участогыннан тыш, аның чикләре территориаль зоналар, урманчылыклар чикләрен кисеп узучы җир участогы булдыру рөхсәт ителми. Җир кишәрлекләренең территориаль зоналар (чикләре әлеге пунктка ярашлы рәвештә территориаль зоналар чикләрен кисеп чыгарга мөмкин булган җир кишәрлекләреннән тыш), урманчылыклар чикләре белән киселешен ачыклаганда, мондый киселешне бетерү федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, җир кишәрлеге төзү өчен киртә булып түбәндәгеләр тормый: җир кишәрлекләре чикләренең территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре, гавами сервитут билгеләнә торган территорияләр чикләре (алга таба - гавами сервитут чикләре), мәдәни мирас объектлары территорияләре, махсус саклanyлучы табигать территорияләре, махсус икътисади зоналар, аучылык җирләре, алдан үстерү территорияләре, Россия Федерациясендә

территориаль үсеш зоналары, уен зоналары, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлау турында карар кабул ителгән территорияләр, Байкал табигый территориясе һәм аның экологик зоналары чикләре белән кисешкән булуы;»;

1.2. 2.8.3.2 пунктның 6.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга: «о) табигый дәвалау ресурсын санитар (тау-санитар) саклау округының беренче зонасы чикләрендә.»;

1.3. 2.8.3.2 пунктның 13 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «13) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогына карата Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктчасының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгының аның эшчәнлеген гамәлгә ашыруы өчен җир участогы бирү турында хәбәр бастырылган һәм урнаштырылган»;

1.4. 7 нче кушымтаның 32 нче пунктындагы 4 нче багананы бәян итәргә: «Бинаның, корылманың, андагы бүлмәләрнең хуҗасы һәм (яисә) дәүләт яки муниципаль милектә булган биналар, корылмалар хуҗалык алып бару хокукында яки Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очракларда оператив идарә итү хокукында арендага бирелгән зат».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов